**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

23 июль 2019 ел №234

Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге Советының 2017 елның 29 августындагы 120 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу яки идарә итү коллегиаль органнары составына керү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июнендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә», Бишнә авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге Советының 2017 елның 29 августындагы 120 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу яки идарә итү коллегиаль органнары составына керү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. нигезләмәнең 1 пунктында "бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы" сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы информация сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда урнаштырырга: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт( авыл мәдәният йорты бинасы).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Бишнэ авыл жирлеге башлыгына йөкләргә.

**Бишнә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **И.М.Фатхуллин**